# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Яту торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

№ 2 28 ноябрь 2025

2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законының 45 нче, 69 нчы маддәләре, "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге" Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Яту торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге Яту торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Яту торак пунктында тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктыртуын агымдагы ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Яту торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Тукай һәм Ю.Гагарин урамнары буенча юлны ремонтлау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Иркәнәш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Иркәнәш авыл җирлеге башлыгы И.З.Камалов